| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ИВАНОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИВАНОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

2023елның 30 октябрендә №49

Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Аккүл торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.2023елның 19 ноябренә Лениногорск муниципаль районы Ивановка авылы җирлеге Аккүл авылында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнарның җыенын 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Сез 2024 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге Ивановка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, күп балалы гаиләләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 1000 (бер мең) сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме:

I. торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Аккүл авылында Колхоз урамы, Комсомол урамы буенча вак таш юлларны чокырлы ремонтлау;

Аккүл авылына юлларны кардан чистарту (Күпер урамы, Колхоз урамы, Комсомол урамы).

II. Җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы итеп, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү:

Аккүл авылы территориясендә үлән чабу;

- триммер өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Ивановка авылы, Яшьлек урамы, 5 йорт адресы буенча урнашкан Ивановка авыл җирлеге администрациясе бинасындагы мәгълүмат стендында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Ивановка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы — А.П. Бодряева